б) эпентеза,

в) редукция,

г) ассимиляция.

**А6.***Саубуллаштык* сүзендә «саңгырау, парлы, кече тел тартыгы» дигән билгеләмәгә туры килгән авазны күрсәтегез:

1.[с]

2.[б]

3.[къ]

4.[ш]

**А7**. *Унбиш* сүзенең язылыш принцибын күрсәтегез.

1. фонетик;
2. морфологик;
3. график;
4. тарихи-традицион.

**А8.** Киң җирдә тар утырсаң, Тар җирдә киң утырырсың. (М)

Бу мәкальдә нинди сүзләр кулланылган?

1. капма-каршы мәгънәле сүзләр;
2. мәгънәдәш сүзләр;
3. аваздаш сүзләр;
4. тамырдаш сүзләр.

**А9.** Фразеологизмның мәгънәсен табыгыз: Санга сукмау-

1. аптырату;
2. эш эшләмәү;
3. хөрмәт итмәү;
4. саный белмәү.

**А10**. Диалекталь сүзне билгеләгез.

1. җыентык
2. җәмәгать
3. җәрен
4. җәйге

**А11**. 1) ау, таш, бер, кул; 2) мәхәббәт, вөҗдан, хыянәт; 3) прогресс, амбулатория.

Бу сүзләрнең бүленеше

а. килеп чыгышы ягыннан

б. кулланылыш сферасына карап

в. кулланылыш активлыгына карап

г. сүзлек хәзинәсенең экспрессив-стилистик катламнары буенча

**А12**.Иртән йокысыннан торып чыккан Нәркәс, бу чәчәк буранын күреп, таң калды (М.Мәһдиев) Чәчәк бураны – нинди метафора?

а. гомумпоэтик метафора

б. автор метафорасы

в. гомумтел метафорасы

**А13.** Метонимиянең бәйләнеш төрен билгеләгез. *Зур зал – зал елый.*

а. эш һәм аның нәтиҗәсе

б. форма һәм аның эчтәлеге

в. материал һәм аннан эшләнгән әйбер

г. урын һәм анда булган процесс.

**А14.** Күчерелмә мәгънәдә бирелгән сүзне табыгыз: *Улының туфлиен күргәч, Гайнетдин башын кашый: Аптыраган бу асфальтка Табанны бик тиз ашый (Ш. Галиев)*

1)башын

2)күргәч

3)табанны

4)ашый

**А15**. *«Кәкре каенга terәтү»* фразеологизмының мәгънәсен күрсәтегез:

1) агач аумасын өчен тотып тору

2)талчыгу, ару 3)алдау

4) күп сөйләү

А16 Ясалма сүзне күрсәтегез:

1) баллы 2) балык

3) балчык 4) бала

**А16**. Кайсы төркемдәге мәгънәле кисәкләрнең бүленеше дөрес?

1. мыгыр-да, мыр-ылда;

2. чыел-да, бөгәр-лә;

3. куна-к, борылма-лы;

4. татарчалат-ып, метрла-п

**А 17**. Рәвешле исем сүзтезмәне табыгыз.

1 күп дуслар;

2 дуслардан бишәү;

3 икенче дусты;

4 дустына бара

**B3.** Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| кояшы баюга тәгәри | 1) фразеологик ныгыма |
| трай тибү | 2) фразеологик бердәмлек |
| көн күрсәтмәү | 3) фразеологик тезмә |
| күз ташлау | 4) фразеологик тәгъбир |

**B4.** Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| балавыз сыгу | 1) тыңлау |
| колак салу | 2) шатлану |
| түбәсе күккә тию | 3) курку |
| кот алыну | 4) елау |

**B5.** Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| Азатлык, бәйлелек | 1) синонимнар |
| Азат, бәйсез | 2) антонимнар |
| Үзегезгә булсын **бүлмәгез,**<br>Юлларымны ләкин **бүлмәгез.** (Ә.Әтнабаев) | 3) омофоннар |
| Елый-елый бу **кыз арган**,<br>Шуңа күрә битләре **кызарган** (Ә.Исхак) | 4) омографлар |

**B6.** Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| Предметның, затның билгесен белдерә торган мөстәкыйль сүз төркеме | 1)алмашлык |
| Предметны һәм затны белдерә торган мөстәкыйль сүз төркеме | 2)исем |
| Исемне, сыйфатны, санны һәм рәвешне алмаштырып килә торган мөстәкыйль сүз төркеме | 3) рәвеш |
| Эш яки хәлнең билгесен белдерә торган мөстәкыйль сүз торкеме | 4) сыйфат |

**B7.** Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| Кызлар, үзара сөйләш-сөйләшә, урамнан баралар | 1)составында исем фигыль булган җөмлә |
| Өч баламны очар кош итеп, Мин очырдым иркен далага (М.Җәлил) | 2) составында шарт фигыль булган җөмлә |
| Эшләмәсәң җәй көне, ни ашарсың кыш көне (М.) | 3) составында хәл фигыль булган җөмлә |
| Син яшәүнең кызыгын белмисен(М.Мәһдиев) | 4) составында сыйфат фигыль булган җөмлә |

**В8.** Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| Дөнья **матур**! | 1)калын хәреф белән бирелгән сүз җөмләдә хәл булып килә |
| Хәдичәттәй **балаларны** әнә шулай шатландыра белә иде (М.Мәһдиев) | 2) калын хәреф белән бирелгән сүз җөмләдә аергыч булып килә |
| **Җиде кат** үлчә, **бер кат** кис (М.) | 3) калын хәреф белән бирелгән сүз җөмләдә тәмамлык булып килә |
| Җанга урын **тапмас** чаклар була. (Зөлфәт) | 4) калын хәреф белән бирелгән сүз җөмләдә хәбәр булып килә |

**В9.** Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| Аерма шунда: без төрле заман кешеләре. | 1)иярчен ия җөмлә |
| Кич җиткәнне мин сизмәдем. | 2) иярчен хәбәр җөмлә |
| Ул килгәндә, мин урамда идем | 3) иярчен тәмамлык җөмлә |
| Кем эшләми, шул ашамый | 4) иярчен хәл җөмлә |

**В10.** Тәңгәллекләр урнаштырыгыз. Җавапта саннар җыелмасын буш аралык калдырмыйча һәм тыныш билгеләрсез языгыз.

| | |
|---|---|
| Барча кош-корт йоклаган булганга, урман тын икән (Г.Тукай) | 1)иярчен вакыт җөмлә |
| Кайчан әйтсән, шул вакытка килермен. | 2) иярчен урын җөмлә |
| Җидегән чишмәләргә йөзек салдым, Җидегән йолдыз күреп калсын дип (Г.Бәширов). | 3) иярчен сәбәп җөмлә |
| Уйсу җирдә су җыела, шунда казлар коена (Җыр). | 4) иярчен максат |

| | |
|---|---|
| | җөмлә |

**В11**. *Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр (Г. Тукай)* җөмләсендә **СТ** калыбына туры килгән ничә иҗек бар? **Җавапны сан белән языгыз**.

**В12.** *Эченә салмасаң, тышына чыкмас* (Мәкаль) җөмләсендә сүз басымы соңгы иҗеккә төшмәгән ничә сүз бар? **Җавапны сан белән языгыз.**

**В13.**Бирелгән рәттә ничә сүз артык: *күренекле, уңган, атаклы, танылган, эшлекле, тырыш, мәшһүр, атказанган*.

**Җавапны сан белән языгыз.**

**В14.***"Салпы ягына... кыстыру"* фразеологик әйтелмәсендә нокталар урынында нинди сүз төшеп калган?

**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**В15.** Тел – кешенең бик борынгы казанышы (М.Зәкиев) җөмләсендә ничә ясалма сүз бар? **Җавапны сан белән языгыз.**

**В16.** Телнел серен белим дисән, Хикмәт телнең төбендә (Н.Арсланов) җөмләсендәге **дисәң** сүзе нинди сүз төркеменә карый?

**Җавап сүзне баш хәрефләр белән языгыз.**

**В17.** “Тәрәзәдән урамга карадым да шаккаттым: агачлар чатыр чабып, куышлы уйнап йөри! Үзем күрмәсәм, ышанмас идем: Галимә әбинең кәҗәсе, сакалын селкетә-селкетә, перәнник ашый, чупыр-чупыр тәмле су эчә, өстәвенә лач-лоч сагыз чәйни” (Л.Лерон) Өзектә ничә затланышсыз фигыль кулланылган? **Җавапны сап белән языгыз.**

**В.18.** “**Хәзер** мин, уеннарымны онытып, **көнозын** колын тирәсендә бөтерелә башладым. **Әүвәле башта**, күз тимәсен өченгә, колынның ялына аллы-кызыллы чуклар бәйләдем” Аерып бирелгән сүзләр нинди сүз төркеменә карый? **Җавапны баш хәрефләр белән языгыз.**

**В19.** *Юк инде ул минем өчен* (Зөлфәт) җөмләсендәге **юк инде** нинди җөмлә кисәге?

**Җавап сүзне баш хәрефләр белән ягыгыз.**

**В20.** “Туса ул, чәчәк бөресе ачылгандай, бары үзеннән үзе һәм үз вакыты белән генә туа ала” (Ә.Еники) җөмләсендә ничә гади җөмлә бар?

**Җавапны сан белән языгыз.**